КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 06 февраль г.Казань № 60

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Амбулаториядә дәвалау вакытында дару чаралары һәм медицина әйберләре табиб рецептлары буенча түләүсез җибәрелә торган авырулар категорияләре исемлеген раслау турында» 2005 ел, 17 гыйнвар, 4 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Амбулаториядә дәвалау вакытында дару чаралары һәм медицина әйберләре табиб рецептлары буенча түләүсез җибәрелә торган авырулар категорияләре исемлеген раслау турында» 2005 ел, 17 гыйнвар, 4 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 16 март, 149 нчы; 2011 ел, 28 апрель, 343 нче; 2017 ел, 15 ноябрь, 879 нчы; 2018 ел, 28 май, 405 нче, 2019 ел, 2 ноябрь, 1007 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктта «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктта «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин